Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Янил авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

2024 елның 15ноябре №8

«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Янил авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресында урнашкан Янил авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 29 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресында урнашкан Янил авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 29 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресында урнашкан Янил авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү);

- урам яктыртуны ясау (Янил авылында урам яктыртуны карап тоту, ясау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Янил авылының Үзәк урамында су белән тәэмин итү системалары төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Янил авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту; юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- тротуарлар ясау, ремонтлау (җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту; тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( йорт төзү, урнаштыру, ремонтлау; Янил авылында күпләп ял итү урыннарын һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Янил авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру) ?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Янил авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893